КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 13 май г.Казань № 437

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлегенә мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү турында» 2014 ел, 27 август, 616 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлегенә мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлегенә мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү турында» 2014 ел, 27 август, 616 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 31 март, 200 нче; 2021 ел, 3 июль, 541 нче; 2021 ел, 11 сентябрь, 857 нче; 2021 ел, 15 ноябрь, 1079 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлегенә мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү тәртибенә, 3.1 пунктның «в» пунктчасындагы өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«индустриаль (сәнәгать) парк территориясе составына сәнәгать инфраструктурасы объектларын урнаштыру рөхсәт ителә торган сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшыру, телевидение, информатика җирләре, космос эшчәнлеген тәэмин итү җирләре, оборона, куркынычсызлык җирләре һәм

башка махсус билгеләнештәге җирләр категориясенә карый торган җир кишәрлекләре керә. Агросәнәгать паркы территориясе составына шулай ук авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясенә карый торган һәм авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүенә бәйле башка максатлар өчен билгеләнгән җир кишәрлекләре керергә мөмкин;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин